ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2020 елның 11 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Бюджет кодексына $9^2$ кушымтага (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 4 – 5; 2005, № 6 (II өлеш), № 10 (I өлеш), № 12 (IV өлеш); 2006, № 6 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2007, № 8, № 10; 2008, № 8 (III өлеш), № 10 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), № 12 (I өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 11 (I өлеш), № 11 (II өлеш); 2012, № 11 (I өлеш); 2013, № 7, № 10, № 11 (I өлеш); 2014, № 5, № 12 (III өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 8 – 9; 2016, № 3, № 6 (III өлеш), № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 19 (I өлеш), № 79 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 5 пунктта:

а) икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$S_i = S_N + S_{SN} + S_K$,»;

б) түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«$S_K$ – i-муниципаль берәмлегенә башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирүче уку-укыту программаларын, шулай ук җайлаштырылган төп гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыра торган муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында педагогика хезмәткәрләренә сыйныф җитәкчелеге өчен айлык акчалата түләүләрне гамәлгә ашыруга субвенция күләме.»;

2) түбәндәге эчтәлекле $7^1$ пункт өстәргә:

«$7^1$. I-муниципаль берәмлегенә башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирүче уку-укыту программаларын, шулай ук җайлаштырылган төп гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыра торган муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында педагогика хезмәткәрләренә сыйныф җитәкчелеге өчен айлык акчалата түләүләрне гамәлгә ашыруга субвенция күләмен исәпләп чыгару түбәндәге формула буенча башкарыла:

$S_K = T_{кр} \times Q \times N_м \times (1+S_{взн}/100\%)$,

монда:

$T_{кр}$ – башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирүче уку-укыту программаларын, шулай ук җайлаштырылган төп гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыра торган муниципаль гомуми белем бирү оешмаларының педагогика хезмәткәрләренә сыйныф җитәкчелеге өчен айлык акчалата түләүләрнең Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгели торган күләме;

Q – i-муниципаль берәмлегендә башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирүче уку-укыту программаларын, шулай ук җайлаштырылган төп гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыра торган муниципаль гомуми белем бирү оешмаларының сыйныф җитәкчелеге өчен айлык акчалата түләүләр ала торган педагогика хезмәткәрләренең фаразлана торган саны;

$N_м$ – башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирүче уку-укыту программаларын, шулай ук җайлаштырылган төп гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыра торган муниципаль гомуми белем бирү оешмаларының педагогика хезмәткәрләренә сыйныф җитәкчелеге өчен айлык акчалата түләүләр гамәлгә ашырыла торган елдагы айлар саны;

$S_{взн}$ – мәҗбүри пенсия иминиятенә, мәҗбүри социаль иминияткә, мәҗбүри медицина иминиятенә иминият кертемнәре тарифларының берләштерелгән күләме, процентларда.».

**2 статья**

Әлеге Закон 2020 елның 1 сентябреннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты

Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2020 ел, 18 июнь
№ 29-ТРЗ